**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«16» февраль 2023 ел Кече Шилнә авылы №47

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 январендәне 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы 3 өлеше 15 пункты нигезендә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 февраленнән Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымталар нигезендә 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. "Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында " ТР Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 январендагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Г. Даутов

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 февралендәге 47 номерлы карарына 1 кушымта

2023 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | |
| 2. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 3974,68 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1558,69 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2260,11 |
| **Барлыгы:** | 7793,48 |

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 февралендәге 47 номерлы карарына 2 кушымта

2023 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кафенгә төрү | 1247 |
| 3. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 2805,65 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1558,66 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2182,17 |
| **Барлыгы:** | **7793,48** |